**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр**
**башкарма комитеты**
**422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района Республики Татарстан**
**исполнительный комитет**
**города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

---

# КАРАР

**«_24_» _апрель__ 2023 ел** **№ _71_**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга агымдагы чыгымнар, сан һәм йөрү нормасы турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларыннан файдалануның шулай ук аларны тотуга чыгымнарның нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аның карамагындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларының сан, йөрү нормасы һәм аларны карап тотуга чыгымнар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 1 декабрендәге 1073 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чаралары белән тәэмин ителү (чикле сан) һәм транспорт чаралары өчен йөрү нормасын 1 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга агымдагы еллык чыгымнар нормасын 2 нче кушымта нигезендә;

-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт

чараларын тотуга агымдагы еллык чыгымнар нормасын, аларны йөртүчеләрсез файдаланганда, 3 нче кушымта нигезендә;

-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан җиңел транспорт чаралары кулланылмаганда, транспорт хезмәтләренә чыгымнар буенча еллык компенсациянең бер төрле күләме нормасын 4 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга еллык чыгымнар нормасын исәпләү тәртибен 5 нче кушымта нигезендә;

- Хезмәт җиңел транспорт чараларын агымдагы карап тотуга чыгымнарны исәпкә алу тәртибе турында нигезләмәне 6 нчы кушымта нигезендә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларының (җиңел автомобильләрнең) йөрү нормасы һәм аларны тоту чыгымнары әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нормадан артмаган күләмдә билгеләнә;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларының әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән йөрү нормасы бер транспорт чарасына билгеләнә;

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларының (җиңел автомобильләрнең) йөреш нормасы һәм аларны карап тоту чыгымнары Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан транспорт чарасының баланста булуына, арендага яисә башка ысул белән файдалануга алынуына бәйсез рәвештә үтәлергә тиеш;

- әлеге карарда хезмәт күрсәтү өчен транспорт чаралары каралган вазыйфаи затлар яки учреждениеләр билгеләнгән нормадан артмаска тиеш;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча әлеге җирле үзидарә органына хезмәт күрсәтүче автомобильләр арасындагы чыгымнарны һәм йөреш нормасын билгеләнгән нормалар чикләрендә бүләргә мөмкин;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы җитәкчесе, транспорт чаралары еллык йөреш нормасын вакытыннан алда үтәгәндә, шул исәптән аларны тиешле максатларда файдаланмау сәбәпле, өстәмә чыгымнарны үз акчасы исәбеннән түли.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы җитәкчесенә транспорт чараларын тотуга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына файдалануга тапшырылган транспорт чараларының фактта булу-

булмавыннан чыгып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына тапшырылган чыгымнар нормасы һәм бюджет ассигнованиеләре күләмнәре чикләрендә әлеге максатларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет язмасында каралган бюджет акчаларының фактта булуыннан чыгып гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе — Р.Ф.Касыймов

Арча шәһәре башкарма комитетының
24 апрель 2023 ел, №_71__ карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чаралары белән тәэмин ителеш (чик саны) һәм транспорт чаралары өчен йөрү нормасы

| N | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы исеме | Хезмәт транспорт чарасын беркетү каралган вазыйфа исеме | Транспорт берәмлекләренең сан нормасы | Транспорт чарасы тибы | Эш сәфәрләрен исәпкә алып, транспорт чараларының елына йөрү нормасы, км | Эш сәфәрләрен исәпкә алып, транспорт чараларының тәүлеккә йөрү нормасы, км |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты | Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе | 1 | Җиңел автомобиль | 24300 | 100 |
| | | Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары | 1 | Җиңел автомобиль | 24300 | 100 |
| | | Дежур автомобиль | 1 | Җиңел автомобиль | 24300 | 100 |

Арча шәһәре башкарма комитетының
24 апрель 2023 ел, №_71__ карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга агымдагы еллык чыгымнар нормасы

| Транспорт чарасы маркасы | Транспорт чарасын тотуга чыгымнарның төп өлеше, елына | 1 км йөрүгә чыгым, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Җиңел автомобиль | | |
| Chevrolet Niva 21230 (ВАЗ-21213) | 235 169 | 6,79 |

Искәрмәләр.

1. Таблицада булмаган транспорт чаралары маркалары өчен егәрлеге һәм двигательнең эш күләме буенча транспорт чараларының аналоглары методын (таблицада китерелгән) кулланып компенсацияләү күләмнәре, шулай ук 100 км йөрешкә ягулык тоту күләме кулланыла.

2. Финанс чыгымнары нормасын билгеләгәндә, бер машина йөртүченең хезмәт хакы исәпкә алынган. машина йөртүченең берничә сменада эшләвен күздә тоткан транспорт чарасын кулланганда, норма машина йөртүчеләрнең өстәмә хезмәт хакы күләменә төзәтелергә тиеш. Машина йөртүчеләрнең хезмәтенә түләү шартларын регламентлаучы норматив хокукый актларда каралган очракларда, күрсәтелгән чыгымнарны финанслауның өстәмә чыганаклары булганда, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитетының норматив-хокукый актында каралган норматив чыгымнардан тыш, хезмәт хакына түләүне башкару рөхсәт ителә. Шул ук вакытта әлеге нормадан тыш чыгымнарны аерым исәпкә алу тәэмин ителә.

3. Автомобильгә техник хезмәт күрсәтүгә һәм ремонтлауга чыгымнар нормасы күләме финанс чыгымнарын билгеләгәндә транспорт һәлакәте һәм транспорт чарасын ремонтлау һәм торгызу зарурлыгына китергән башка вакыйга нәтиҗәсендә транспорт чарасын ремонтлауга һәм торгызуга бәйле чыгымнарны үз эченә алмый.

4. Әлеге искәрмәләрнең 3 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны гамәлгә ашырганда, нормативтан тыш чыгымнарны аерым исәпкә алу тәэмин ителә.

5. Финанс чыгымнары нормативларын билгеләгәндә автомобильгә бер техник хезмәт күрсәтү бәясе исәпкә алынган. Автомобильнең еллык норматив йөгереше 15,0 мең км дан артып киткән очракта, машинага техник хезмәт күрсәтүгә чыгымнар 2.5 пункты нигезендә исәпләнелә. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган аларга буйсынучы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибе.

Арча шәһәре башкарма комитетының
24 апрель 2023 ел, №_71__ карарына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга агымдагы еллык чыгымнар нормасы (аларны йөртүчеләрсез файдаланганда)

| Транспорт чарасы маркасы | Транспорт чараларын тотуга чыгымнарның төп өлеше, елына | 1 км йөрүгә чыгым, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Җиңел автомобиль | | |
| Chevrolet Niva 21230 (ВАЗ-213) | 39 480 | 6,79 |

Искәрмәләр.

1. Йөртүчедән башка җиңел транспорт чаралары гына куллану рөхсәт ителә.

2. Таблицада булмаган транспорт чаралары маркалары өчен егәрлеге һәм двигательнең эш күләме буенча транспорт чараларының аналоглары методын (таблицада китерелгән) кулланып компенсацияләү күләме, шулай ук 100 км йөрешкә ягулык тоту күләме кулланыла.

3. Финанс чыгымнары нормативларын билгеләгәндә, автомобильгә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлауга чыгымнар күләме нормасы транспорт һәлакәте һәм транспорт чарасын ремонтлау һәм торгызу кирәклегенә китергән башка вакыйга нәтиҗәсендә транспорт чарасын ремонтлау һәм торгызу белән бәйле чыгымнарны үз эченә алмый.

4.Әлеге искәрмәләрнең 3 пунктында курсәтелгән чыгымнарны гамәлгә ашырганда, нормативтан тыш чыгымнарны аерым исәпкә алу тәэмин ителә.

5. Финанс чыгымнары нормаларын билгеләгәндә, автомобильгә бер техник хезмәт күрсәтү бәясе исәпкә алынган. Автомобильнең еллык йөгереш нормасы15,0 мең км дан артып киткән очракта, автомобильгә техник хезмәт күрсәтүгә чыгымнар 2.5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм һәм аларга буйсынучы учреждениеләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган транспорт чараларына еллык чыгымнар нормасын исәпләү тәртибенең 2.5 пункты нигезендә исәпләнә.

Арча шәһәре башкарма комитетының
24 апрель 2023 ел, №_71_ карарына
4 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан җиңел транспорт чаралары кулланмаганда, транспорт хезмәтләренә чыгымнар буенча еллык компенсациянең бер төрле күләме нормасы

Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитетының норматив хокукый актында җиңел машина беркетү каралган очракта, әмма учреждение яисә вазыйфаи зат шәхси җиңел машинаны хезмәт максатларында файдаланганда яки башка оешмаларның транспорт хезмәтләреннән файдаланганда, мондый учреждение яисә вазыйфаи зат өчен хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган сигез сәгатьлек эш көнендә көнгә 506,4 сум күләмендә өчен компенсация (алга таба - компенсация) алу каралган. Эш көненең озынлыгы сигез сәгатьтән арткан очракта, эш көненең факттагы дәвамлылыгына карата сигез сәгатькә тигез булган коэффициент кулланыла.

Компенсация җиңел автомобильләр өчен генә карала һәм Арча муниципаль районының норматив хокукый акты белән билгеләнгән җиңел автомобильләрнең норматив саны кысаларында гына рөхсәт ителә. Арча муниципаль районының норматив хокукый акты белән җиңел автомобильләрне беркетү каралмаган учреждениеләр яисә вазыйфаи затлар өчен компенсация алу рөхсәт ителми.

Компенсация кулланылучы җиңел автомобиль маркаларына карамастан, бер төрле, һәм учреждение яисә вазыйфаи зат тарафыннан шәхси җиңел автомобильдән хезмәт максатларында файдалануның яисә чит оешмаларның транспорт хезмәтләреннән файдалануның тулы көннәрен исәпкә алып түләнә.

Арча шәһәре башкарма комитетының
24 апрель 2023 ел, №__71_ карарына
5 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын тотуга еллык чыгымнар нормасын исәпләү тәртибе

1. Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибе Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына һәм аның карамагындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче, шулай ук Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне тотуга бирелә торган чыгымнар нормасын исәпләү тәртибен (алга таба - Тәртип) билгели.

2. Җиңел автомобильләрне тоту чыгымнары 1 км арага транспорт чарасын тотуга һәм эксплуатацияләүгә чыгымнарның төп өлешенә бүленә.

Транспорт чарасын тотуга чыгымнарның төп өлеше транспорт чарасын эксплуатацияләү елына исәпләнә һәм түбәндәге чыгымнарны үз эченә ала:

машина йөртүченең хезмәт хакы, шул исәптән иминият кертемнәре (З1, З2); транспорт салымы (З3);

автогражданлык җаваплылыгын иминиятләштерү (З4); автомобильгә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (З 5); автомобильне техник карау (З6);

машина йөртүчегә туклану һәм яшәү өчен эш сәфәре чыгымнары (З 7).

Транспорт чарасын файдалануга 1 км арага киткән чыгымнарга түбәндәгеләргә чыгымнар кертелә:

2.1. Машина йөртүченең хезмәт хакы (З1) Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә исәпләнә. Машина йөртүченең хезмәт хакы 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларына каршы килә алмый.

2.2. Иминият кертемнәре (З2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә исәпләнә.

2.3. Транспорт салымы (З3) "Транспорт салымы турында" 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы исәпләнә.

2.4. Автогражданлык җаваплылыгын иминиятләштерүгә чыгымнар (З4) һәр транспорт чарасы өчен фактлар буенча кабул ителә. Яңа файдалануга

тапшырыла тора автомобильләр өчен елына 13 680 сумга тигез зурлык кабул ителә.

2.5. Автомобильгә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлауга чыгымнар нормасы күләме (З5) беренчел бәясе 1,2 млн сумнан артмаган автомобильләр өчен елына 9 600 сумга һәм бәясе 1,2 млн сумга тиң яки аннан кыйммәтрәк автомобильләр өчен елына 25 920 сумга тиң дип кабул ителә.

2.6. Автомобильне техник карау чыгымнары (З6) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында транспорт чараларын техник карау өчен түләүнең чик күләмнәрен билгеләү турында" 27.12.2011 № 1079 карарына ярашлы кабул ителә.

2.7. Машина йөртүчегә туклану һәм яшәү өчен эш сәфәре чыгымнары (З7) елына 14 976 сумга тиң дип кабул ителә (бу максатларга Татарстан Республикасы Бюджет оешмалары тарафыннан сарыф ителә торган уртача статистик зурлык буларак).

2.8. 2.8. 1 км йөгерешкә автомобиль шиннары сатып алу чыгымнары (З 8) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$З_8 = Ст_{ш} \times К_{ш} / 60\ 000,$$

биредә:

Стш -бер автомобиль шинның уртача бәясе (җәйге һәм кышкы шиналарны алыштыру кирәклеген исәпкә алып), сум;

Кш- бер автомобиль өчен кирәкле шиннар саны; 60 000 шин өчен норматив йөгереш, км.

2.10. 1 км йөрешкә ягулык-майлау материалларына чыгымнар (З 9) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$З9 = Qнорм / 100 \times Сттопл \times Кмасл,$$

биредә:

$Q_{норм}$ - транспорт чарасының ягулык чыгымы нормасы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Q_{норм} = Q_{баз} \times (1 + 0,01 \times D),$$

биредә:

$Q_{баз}$ - ягулык кулланунын төп нормасы, л/100 км;

D - нормага карата төзәтмә коэффициент (суммар чагыштырма өстәмә яки киму);

$Ст_{топл}$ - алдагы чор ахырына автомобиль ягулыгының уртача статистик бәясе, Татарстанстат мәгълүматларына ярашлы кабул ителә, сум;

$К_{масл}$ - автомобиль майларына чыгымнар коэффициенты 1,08 дип кабул ителә.

Q баз һәм D зурлыклары Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2008 елның 14 мартындагы«Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материаллары тоту нормасы» методик тәкъдимнәрен гамәлгә кертү турында» АМ-23-р карарында күрсәтелгән нормаларга ярашлы кабул ителә.

2.9. 1 км йөрешкә башка чыгымнар (З 10) автомобиль өчен вак комплектлаучыларны алыштыру чыгымнарын үз эченә ала һәм формула буенча исәпләнә:

$$З_{10} = (З_8 + З_9) \times 0{,}07.$$

3. Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне тотуга норматив еллык чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$НФЗ_{В1} = \square З_i + \square\square З_i \square \times Пр_{норм},$$

$$7 \quad i=1^{10} \quad i=8$$

биредә $Пр_{норм}$ - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты норматив хокукый акты белән расланган еллык йөреш нормасы.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнар аларны йөртүчеләрсез кулланганда (НФЗВ2) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

7

$$НФЗВ2 = = \square Зi + + \square\square Зi \square \times Прнорм$$

$$i=3 \quad i=8$$

Арча шәһәре башкарма комитетының
24 апрель 2023 ел, №_71__ карарына
6 нчы кушымта

Хезмәт җиңел транспорт чараларын агымдагы тоту чыгымнарын исәпкә алу тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә (алга таба-Нигезләмә) Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә башкарма органнары (алга таба - башкарма органнар) тарафыннан транспорт чараларының балансыта булуына, арендага яисә башка ысул белән файдалануга алынуына карамастан, хезмәт җиңел автомобильләрен тоту чыгымнарын исәпкә алу тәртибен билгели.

2. Башкарма органнар һәм аларга буйсынган учреждениеләр, транспорт чаралары балансыта булуына, арендага яисә башка ысул белән файдалануга алынуына карамастан, транспорт чараларының фактта йөрүен көндәлек исәпкә алалар.

Башкарма органнар үз балансындагы хезмәт җиңел автомобильләрен тотуга чыгымнарны башкарма органнар, хезмәт җиңел автомобильләре һәм чыгым төрләре (өстәмә икътисади классификация) киселешендә исәпкә алалар.

3. Башкарма органнар ай саен җиңел автомобильләрне тоту чыгымнарын исәпкә алу белешмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитетының норматив хокукый акты белән расланган чыгымнар нормасының факттагы чыгымнарга карата экономиясен яисә чыгымнар нормасының артуын ачыклау предметына анализ ясыйлар.

4. Башкарма органнар җитәкчеләренә хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр ай саен тиешле башкарма органнарга хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне агымдагы тотуга киткән факттагы чыгымнар турында мәгълүмат җиткерә.

5. Башкарма органнар җитәкчеләре, балансыта торучы һәм тиешле башкарма органнарга хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрдән файдалануны тикшереп торуны оештыру максатыннан, хезмәт җиңел автомобильләренең фактта йөрүен көндәлек исәпкә алалар, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитетының норматив хокукый акты белән расланган норматив чыгымнарны нигезсез арттыруга бәйле рәвештә чыгымнарны каплауга юнәлдерелгән чаралар күрүне тәэмин итәләр.

6. Башкарма органнар тарафыннан җиңел автомобильләрне тоту чыгымнарын исәпкә алу расланган нормалар чикләрендә башкарма органнар киселешендә гамәлгә ашырыла.

Хезмәт җиңел автомобильләрен тоту чыгымнарын исәпкә алу расланган нормалар чикләрендә һәм башкарма органнар киселешендә гамәлгә ашырыла.

7. Башкарма органнар хисап кварталыннан соң килгән айның 25 енә кадәр квартал саен «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә хезмәт җиңел автомобильләре һәм чыгым төрләре буенча үсә барган нәтиҗә белән хезмәт җиңел автомобильләрен тоту чыгымнары турында хисап

тапшыралар (өстәмә икътисади классификация).